МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 150 / о

П Р И К А З

Б О Е Р Ы К

« 30 » 09 2021

Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.
2. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.
3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә капиталь төзелеш объектын төзү планлаштырылган очракта һәм Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектын үзгәртеп кору очрагында, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук шәхси автомобиль юлларын төзү, үзгәртеп корудан тыш, әгәр төзүне, үзгәртеп коруны Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территорияләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылса, капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 24 маендагы 89/о номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 30 сентябрендәге 150/о номерлы боерыгы белән расланды

**Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент), капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территориясендә планлаштырылса, региональ һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук, әгәр төзү, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территориясендә планлаштырылса, шәхси автомобиль юлларын, төзү, үзгәртеп корудан тыш, капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: юридик һәм физик затлар, шәхси эшкуарлар (алга таба – Мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүче исеменнән юридик зат җитәкчесе яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат ышаныч кәгазе яисә үзенең шәхесен таныклаучы документлар нигезендә эш итә.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат бирү:

1.3.1. дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат түбәндәгечә урнаштырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдәге бүлмәләрдә урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларында;

2) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://www.minstroy.tatarstan.ru);

3) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru) (алга таба – Республика порталы);

4) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм

порталында (https://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал);

5) «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Республика реестры).

1.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү түбәндәгеләрдә гамәлгә ашырыла:

1) телдән – шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать иткәндә – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә;

2) Республика порталының интерактив формасында;

3) Министрлыкта:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ форматында) – почта аша кәгазьдә, электрон почта буенча электрон формада.

1.3.3. Бердәм порталда, Республика порталында Республика реестрында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.

1.3.4. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать иткән очракта, алынган мөрәҗәгать нигезендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең, Министрлыкның урнашкан урыны турында (адресы, эш графигы, белешмә телефоннары); дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында, гаризаларны тапшыру ысуллары һәм сроклары турында; дәүләт хезмәте күрсәтелә торган граждан категорияләре турында; дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар турында; дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны карау өчен кирәкле документлар исемлеге турында, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары турында; дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында; дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча рәсми сайтта мәгълүмат урнаштырылган урын турында; Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә яки гамәл кылмавына шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат җиткерелергә мөмкин.

Язма мөрәҗәгать буенча Министрлыкның Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең территорияләрне планлаштыру һәм төзү бүлегенең (алга таба – Бүлек) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затлары мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен һәм Регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне язмача аңлата һәм Министрлыкның эшчәнлек башкару күрсәтмәсендә билгеләнгән срок эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар мөрәҗәгать итү телендә бирелә. Мөрәҗәгать итү телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләренә бәйле мәгълүматлар Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Министрлыкның мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте күрсәтү турында әлеге Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында булган белешмәләрне, Министрлыкның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш вакыты турында, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү графигы турында мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырылган.

Әлеге Регламент тексты Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырылырга тиеш.

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

мөрәҗәгать итүче – дәүләт хезмәте күрсәтү турында телдән, язма яки электрон формада гариза белән мөрәҗәгать иткән физик яки юридик затлар (дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан тыш) яисә аларның вәкаләтле вәкилләре;

төзүче – үзенә караган җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны, капиталь ремонтлауны, шулай ук инженерлык эзләнүләрен башкаруны, әлеге объектларны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау өчен проект документлары әзерләүне гамәлгә ашыра торган физик яки юридик зат.

техник заказчы – төзүче тарафыннан вәкаләт бирелгән һәм инженерлык эзләнүләрен башкару турында, проект документларын әзерләү турында, капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау турында төзүче исеменнән шартнамәләр төзи торган, эшләрнең күрсәтелгән төрләрен башкаруга йөкләмәләр әзерли, капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау буенча инженерлык эзләнүләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерли торган затларга эшләрнең әлеге төрләрен башкару өчен кирәкле материалларны һәм документларны тапшыра, проект документларын раслый, капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыру өчен рөхсәт алуга кирәкле документларны имзалый, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы) каралган башка функцияләрне һөнәри нигездә эш итеп гамәлгә ашыра торган физик зат яисә юридик зат. Төзүче техник заказчы функцияләрен мөстәкыйль башкарырга хокуклы.

Төзелешкә рөхсәт капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проектында каралган бөтен срокка бирелә, мондый рөхсәт төзүнең, үзгәртеп коруның аерым

этапларына бирелә торган искәрмәле очраклардан тыш. Индивидуаль торак төзелешенә рөхсәт ун елга бирелә.

Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты төзүченең мондый рөхсәтнең гамәлдә булу чоры беткәнчегә кадәр кимендә алтмыш көн алдан бирелгән гаризасы буенча арттырылырга мөмкин. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору мондый гариза бирү вакыты чыкканчы башланмаган очракта, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттырудан баш тартыла.

Төзелешкә рөхсәт бирү түбәндәге очракта таләп ителми:

1) физик затка эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга яки бакчачылык һәм яшелчәчелек өлкәсендәге законнар нигезендә билгеләнгән, бакчаның җир кишәрлегендә торак йорт, бакча йорты, хуҗалык корылмалары төзүгә, үзгәртеп коруга бәйле булмаган максатлар өчен тапшырылган җир кишәрлегендә гараж төзелгән, үзгәртеп корылган очракта;

1.1) индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, үзгәртеп кору очракларында;

2) капиталь төзелеш объектлары булмаган объектларны төзү, үзгәртеп кору очрагында;

3) җир кишәрлегендә ярдәмче файдалану төзелмәләре һәм корылмалары төзелгән очракта;

4) капиталь төзелеш объектларын һәм (яки) аларның өлешләрен үзгәртү очрагында, әгәр мондый үзгәртүләр аларның конструктив һәм ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгы буенча башка характеристикаларына кагылмаса һәм шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән, рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларын арттырмаса;

4.1) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау очрагында;

4.2) файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проекты яки җир асты байлыклары участокларыннан файдалануга бәйле эшләрне башкару өчен җир асты байлыклары турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән, килештерелгән һәм расланган бораулау скважиналарын төзү, үзгәртеп кору очрагында;

4.3) чит илләрдә Россия Федерациясе илчелекләрен, консуллыкларын һәм вәкиллекләрен төзү, үзгәртеп кору очрагында;

4.4) 1,2 мегапаскальгә кадәр (иң күбе) басым астында табигый газны транспортлау өчен билгеләнгән объектларны төзү, үзгәртеп кору очрагында;

4.5) элемтә чараларын урнаштыру өчен билгеләнгән 50 метр биеклектәге антенна баганалары (мачталар һәм манаралар) урнаштыру очрагында;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелешкә рөхсәтләр бирү таләп ителми торган объектлар исемлеген раслау турында» 2011 елның 24 июнендәге 1038-р номерлы күрсәтмәсендә билгеләнгән башка очракларда.

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары

белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

ИАБС – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар (мөрәҗәгать итүче гражданнар һәм башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары) өчен дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматтан санкцияле рәвештә файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

Күпфункцияле үзәк – «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе;

Автоматлаштырылган мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атылышы

Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) (алга таба – төзелешкә рөхсәт)

2.2. Башкарма хакимият органы исеме

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) төзелешкә рөхсәт;
2) төзелешкә гамәлдә булу чоры арттырылган рөхсәт;

3) кертелгән үзгәрешләре белән төзелешкә рөхсәт;

4) төзелеш өчен рөхсәт нөсхәсен кабат (дубликат) бирү;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә Министрлыкның вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында Бердәм порталда, Республика порталындагы мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Министрлык тарафыннан җибәрелгән, күпфункцияле үзәкнең мөһере һәм күпфункцияле үзәк хезмәткәренең имзасы белән таныкланган, кәгазьдә бастырылган электрон документ нөсхәсе рәвешендә күпфункцияле үзәктән дә алына ала.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гамәлдә булган чор дәвамында электрон документ яки кәгазьдәге электрон документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты:

төзелешкә рөхсәт бирү – гариза бирү көнен дә кертеп, биш эш көне. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гариза теркәлгәннән соң икенче көннән башлап исәпләнә.

төзелешкә рөхсәт вакытын арттыру – биш эш көне.

төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү – биш эш көне.

төзелешкә рөхсәт дубликатын бирү – өч эш көне.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ формасында җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе.

2.5.1. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору очрагында мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

1) төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза:

кәгазь документ формасында (әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә);

63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада;

2) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләнүе турында килешү, гавами сервитут билгеләнүе турында карар, шулай ук, РФ Шәһәр төзелеше кодексының $57^3$ статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта, җир кишәрлеге оештыруга нигез булган һәм җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы бирелгән территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашкан схема, әгәр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $7^3$ өлешендә башкача билгеләнмәсә;

2.1) Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән очракларда, дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), бюджетка карамаган дәүләт фондының идарә органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән килешү булган очракта, – әлеге килешү, үзе белән әлеге килешү төзелгән хокук иясенең җир кишәрлегенә хокукын билгели торган документлар;

3) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм расланган проект документларындагы түбәндәге материаллары (әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) бәяләмәләрнең бердәм дәүләт реестрында булмаса):

а) аңлатма язуы;

б) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир кишәрлеген оештыруны планлаштыру схемасы, ә линияле объектларга карата проект документациясе әзерләнгән очракта территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган аерып чыгару полосасы проекты (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документация таләп ителми торган очраклардан тыш);

в) архитектура һәм корылма чишелешләрен, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чишелешләрне һәм чараларны үз эченә алган бүлекләр (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эш, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектлар, торак фонды объектларына карата проект документлары әзерләнгән очракта);

г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (башка капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору өчен капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү зарурлыгы булган очракта, капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проектын да кертеп);

4) капиталь төзелеш объекты үзгәртеп корылган очракта, мондый объектның барлык хокук ияләренең ризалыгы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 6 өлешендәге $6^2$ пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортны үзгәртеп кору очракларыннан тыш;

4.1) хокук иясе булып дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе, дәүләт (муниципаль) бюджет яки автоном учреждение торган, үзенә карата әлеге орган, тиешенчә, гамәлгә куючы функцияләрен яки мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт милкендәге (муниципаль милектәге) капиталь төзелеш объектында дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы) булып торган

дәүләт (муниципаль) заказчысы, «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, бюджетныкы булмаган дәүләт фондының идарә органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан үзгәртеп кору уздырылган очракта, – мондый үзгәртеп коруны уздыру турында, шул исәптән үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда әлеге объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртибен дә билгели торган, килешү;

4.2) күпфатирлы йорт үзгәртеп корылган очракта, күпфатирлы йортта урыннар һәм машина урыннары милекчеләренең торак законнары нигезендә кабул ителгән гомуми җыелышы карары яки, мондый үзгәртеп кору нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнең күләме кимесә, күпфатирлы йортта урыннарның һәм машина урыннарының барлык милекчеләренең ризалыгы;

5) проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертиза буенча уңай бәяләмә бирүче юридик затның аккредитация турында таныклык күчермәсе, әгәр проект документларына карата дәүләтнеке булмаган экспертиза бәяләмәсе тапшырылган булса;

6) мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар, әгәр мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр уздырылганда мондый объектның ышанычлы һәм куркынычсыз булуына кагылышлы конструктив һәм башка сыйфатламалары кузгатылса.

2.5.2. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыру зарурлыгына бәйле рәвештә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертелгәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

1) төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыру зарурлыгына бәйле рәвештә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза (әлеге Регламентка 2 нче кушымта). Гариза рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты беткәнчегә кадәр кимендә 10 эш көне алдан бирелә;

2) шәхесне яки вәкаләтләрен раслый торган документлар;

3) төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты өлешендә төзәтмә кертелгән капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты;

4) төзүченең капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча эшләр башлануы турында белдерү күчермәсе, аны алу турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тамгасы белән;

2.5.3. Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр керткәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

Җир кишәрлекләренә хокукларның, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының мөрәҗәгать итүчегә күчүе турында, җир кишәрлеге оештыру турында язмача формада белдерү, түбәндәгеләрнең реквизитларын күрсәтеп:

1) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^5$ өлешендә күрсәтелгән очракта, мондый җир кишәрлекләренә хокук билгели торган документлар;

2) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^6$ һәм $21^7$ өлешләрендә каралган очракларда, әгәр җир законнары нигезендә җир кишәрлеген оештыру турындагы карарны дәүләт хакимияте башкарма органы яки җирле үзидарә органы кабул итсә, җир кишәрлекләрен оештыру турындагы

карарлар;

3) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^7$ өлешендә каралган очракта, капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы;

4) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^9$ өлешендә каралган очракта, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында карар һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карар;

2.5.4. Төзелешкә рөхсәт дубликатын биргәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

1) гариза;

2) шәхесне яки вәкаләтләрне раслый торган документлар.

2.5.5. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать итү яисә почта аша кәгазьдә һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрү юлы белән;

2) күпфункцияле үзәк белән Министрлык арасында үзара хезмәттәшлек турындагы килешү нигезендә күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә һәм әлеге Регламентның 2.5.6 пункты таләпләренә туры килә торган электрон документлар рәвешендә;

3) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, электрон формада.

2.5.6. Гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, физик затлар һшм шәхси эшкуарлар гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Гариза Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче документларның электрон рәвешләрен яисә 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә мондый документларны төзү һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган электрон формадагы документларны тапшыра.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе;

әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Төзелешкә рөхсәт бирелгән очракта, вәкаләтле органнардан түбәндәге документлар (белешмәләр) соратып алына:

1) күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә алган Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

2) төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза тапшырылган көнгә кадәр кимендә өч ел алдан алынган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы яки, линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проектының һәм территорияне ызанлау проектының реквизитлары (линияле объект төзелеше, аны үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), урнаштырылуы өчен җир кишәрлеген оештыру таләп ителми торган линияле объект төзелеше өчен рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проектының реквизитлары;

3) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору өчен нигез булган проект документларының уңай экспертиза бәяләмәсе (проект документларының РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе өлешендә), шул исәптән, әгәр әлеге проект документларынд, линияле объектларны да (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $12^1$ өлешендә каралган очракта, аерым төзелеш этапларына карата) кертеп, башка капиталь төзелеш объектларын төзү яки үзгәртеп кору да каралган булса, әгәр мондый проект документлары РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертизага тиешле булса, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 34 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе (әгәр әлеге документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) бәяләмәләрнең бердәм дәүләт реестрында булмаса);

3.1) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 38 өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, проект документларына кертелә торган, проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затлардан тупланган әгъзаларга нигезләнгән үзкөйләнешле оешма әгъзасы булып торган зат тарафыннан тапшырылган һәм әлеге зат тарафыннан РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектлавын оештыру буенча белгеч буларак җәлеп ителгән зат тарафыннан расланган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 38 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүенә раслама;

3.2) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 39 өлеше нигезендә экспертлар белән бергә эшләү барышында проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, проект документларына кертелә торган, башкарма хакимият органы яки проект документларына экспертиза уздырган оешма тарафыннан

тапшырылган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 39 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүенә раслама;

4) рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору буенча чик дәрәҗә параметрлардан тайпылуга рөхсәт (әгәр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40 статьясына ярашлы рәвештә төзүчегә андый рөхсәт бирелгән булса);

5) ярашлылык сертификатларының бердәм реестрыннан белешмәләр;

6) урнаштырылуына бәйле рәвештә Россия Федерациясе законнары нигезендә территориясеннән файдалануда махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиешле капиталь төзелеш объекты төзелгән яки, нәтиҗәдә үзгәртеп корылачак объектка карата территориядән файдалануда махсус шартлары булган зона билгеләренергә яки элегрәк билгеләнгән территориядән файдалануда махсус шартлары булган зона үзгәртелергә тиешле капиталь төзелеш объекты үзгәртеп корылган очракта, территориядән файдалануда махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карар күчермәсе;

7) җирле үзидарә органы тарафыннан территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору планлаштырылган очракта, территорияне үстерү турында килешү күчермәсе (территорияне комплекслы үстерү турындагы карар Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яки муниципаль берәмлек тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырылган яки мондый карар РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә билгеләнгән юридик зат яки Россия Федерациясе субъекты тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш).

2.6.2. Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертелгән очракта (кертелә торган үзгәрешләргә карап) вәкаләтле органнардан түбәндәге документлар (белешмәләр) соратып алына:

1) күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә алган Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

2) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^6$ һәм $21^7$ өлешләрендә каралган очракларда, әгәр җир законнары нигезендә җир кишәрлеген оештыру турындагы карарны дәүләт хакимияте башкарма органы яки җирле үзидарә органы кабул итсә, җир кишәрлекләрен оештыру турындагы карарлар;

3) бүлү, үзгәртеп бүлү, аерып чыгару вакытында булдырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы;

4) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^9$ өлешендә каралган очракта, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында карарлар һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карарлар.

2.6.3. Гаризаны тапшырган вакытта мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.6.1, 2.6.2 пунктларында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган электрон документлар рәвешендә бирергә хокуклы.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт органнары, җирле үзидарә

органнары һәм дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булган белешмәләрне үз эченә алган документларның тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе булып тормый.

2.6.5. Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

1) мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

2) документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

3) тапшырылган документлар яисә белешмәләрнең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән вакытта үз көчләрен югалтуы (шәхесне раслаучы документ белешмәләре; мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта);

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү

өчен кирәкле документларның билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада тапшырылуы;

5) әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшырмау;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына тапшырылуы;

7) гариза һәм документларның (документлар күчермәләренең) 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләренә туры китереп гади электрон имза белән имзаланмаган (танылганмаган булуы) (гаризаны электрон формада тапшырган очракта).

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентка 4 нче кушымтада билгеләнгән формага туры китереп рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне, мөрәҗәгать итүченең ихтыярына карап, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетка һәм (яки) күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

2.7.3. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

2.8.2. Төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту нигезләре:

1) линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, тапшырылган документларның территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты (линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру документлары таләп ителми торган очраклардан тыш) таләпләренә, шулай ук җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану таләпләренә һәм (яки) Россия Федерациясенең җир турындагы һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә һәм төзелешкә рөхсәт бирү датасына гамәлдә булган рөхсәтле төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга бирелгән рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

2) территорияне комплекслы үстерү турындагы килешү нигезендә расланган территорияне планлаштыру документларының булмавы (территорияне комплекслы үстерү турындагы карар Татарстан Республикасы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырылган яки мондый карар РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә билгеләнгән юридик зат яки Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырылган очраклардан тыш).

3) дәүләт хакимияте органыннан, җирле үзидарә органыннан яисә дәүләт хакимияте органына яки җирле үзидарә органына буйсына торган оешмадан

ведомствоара рәсми мөрәҗәгатькә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында таныклый торган җавап килүе, яисә тиешле документның мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмавы.

2.8.3. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыру зарурлыгына бәйле рәвештә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү очрагында, баш тарту нигезләре:

1) хокук күчүе турында хәбәрләмәдә күрсәтелгән белешмәләрнең төгәл булмавы;

2) планлаштырылган капиталь төзелеш объектын урнаштыруның капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^7$ өлешендә каралган очракта, җир кишәрлеге оештыруның шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве. Бу вакытта җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{10}$ өлешендә күрсәтелгән белдерү җибәреләсе көнгә кадәр кимендә өч ел алдан бирелгән булырга тиеш;

3) Министрлыкта дәүләт төзелеш күзәтчелеге, дәүләт җир күзәтчелеге яки муниципаль җир контроле кысаларында төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтуга бәйле рәвештә төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризаны тапшыру көненә төзелеш, үзгәртеп кору буенча башланган эшләрнең булмау фактын ачыклау турында мәгълүмат яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 5 өлешендәге таләпләр нигезендә мондый белдерүне җибәрү мәҗбүри булып торса, әлеге эшләрне башлап җибәрү турында белдерү булмавы турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органыннан мәгълүмат булуы, әгәр төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтуга бәйле булса. Бу очракта Министрлык, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлек итүнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан да файдаланып, тиешле дәүләт хакимияте органыннан яки җирле үзидарә органыннан шундый мәгълүматны соратып ала;

4) төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланырга ун эш көненнән азрак вакыт калгач төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озынайтуга бәйле рәвештә төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза тапшырылуы.

2.8.4. Төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертелгән очракта, баш тарту нигезләре:

1) җир кишәрлегенә хокук, җир асты байлыкларыннан файдалануга хокук күчүе, җир кишәрлеге оештыру турындагы белдерүдә РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{10}$ өлешендәге 1-4 пунктларына ярашлы рәвештә күздә тотылган документларның реквизитлары булмау, яисә РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{13}$ өлешендә күрсәтелгән очракта, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документның булмавы;

2) җир кишәрлегенә хокукларның, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының күчүе, җир кишәрлеге оештыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән

белешмәләрнең дөрес булмавы;

3) планлаштырылган капиталь төзелеш объектын урнаштыруның капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{7}$ өлешендә каралган очракта, җир кишәрлеге оештыруның шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве. Бу вакытта җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{10}$ өлешендә күрсәтелгән белдерү җибәреләсе көнгә кадәр кимендә өч ел алдан бирелгән булырга тиеш;

4) планлаштырылган капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм (яки) Россия Федерациясенең җир турындагы һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $21^{7}$ өлешендә каралган очракта, төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү датасына гамәлдә булган чикләмәләргә туры килмәве;

5) планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын урнаштыруның рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

6) төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризаның төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланырга ун эш көненнән азрак вакыт калгач тапшырылуы.

2.8.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар, сәбәпләрен күрсәтеп, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетка яки күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

2.8.6. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела

2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм аны алу нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан чират көтүнең максималь вакыты унбиш минуттан артык булырга тиеш түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

2.13.1. Гариза һәм документлар килгән көнне.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан, гариза тапшырылган көнне, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан, теркәү номеры, гаризаны тапшыру датасы һәм тапшырылган документлар исемлеге белән язу тапшырыла.

2.13.2. Күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза тапшырылган көнне мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү номеры һәм электрон гаризаны тапшыру датасы белән Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан язу бирелә.

2.13.3. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән файдалану һәм хезмәт

күрсәтә алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.14.3.Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, җирле үзидарәнең үтәү-боеру органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документлар кабул ителә, бирелә торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

2) белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;

3) мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

4) гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

5) Министрлык биналарын һәм бүлмәләрен инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген бирә торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү, шулай ук инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеген бирә торган башка шартлар үтәлешен тәэмин итү;

6) инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;

3) Министрлык хезмәткәрләренең Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның вазыйфаи затлары белән үзара бәйләнешкә керү саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) барлык кирәкле документлар белән гариза тапшырылганда, – бер тапкыр;

4.2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алган очракта, – бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә үзара хезмәттәшлек итүнең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә хокуклы.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинеттан, Министрлыктан, күпфункцияле үзәктән алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә тиешле гамәл ахырына җиткереп үтәлгәннән соң бер эш көненнән дә артмаган вакытта электрон почта адресына яисә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, Бердәм портал, Республика порталы, Министрлыкның рәсми сайты чараларыннан файдаланып җибәрелә.

2.15.4. Дәүләт хезмәте, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аның яшәгән урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүче комплексглы рәсми мөрәҗәгать составында дәүләт

хезмәте күрсәтүгә хокуклы.

2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр

2.16.1. Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә консультация бирелергә мөмкин.

2.16.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.16.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.16.4. Мөрәҗәгать итүчеләрне Министрлыкта, күпфункцияле үзәктә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язылу) Бердәм портал, Республика порталы аша, Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең элемтә үзәге телефоны буенча гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге дата башланырга бер тәүлек калгач бетә.

Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

(фамилиясе, исемен һәм атасының исемен (булган очракта))

телефон номеры;

электрон почта адресы (ихтыяры буенча);

кабул итүнең теләнгән датасы һәм вакыты.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Кабул итүгә алдан язылган вакытта билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү;

2) мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәк хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә – Бүлек хезмәткәре.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап, күпфункцияле үзәккә шәхсән үзе һәм телефон һәм

электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны КФҮнең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документлар формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән, телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, Министрлык сайтыннан консультация алырга хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә мәгълүмат җиткерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать алынган көннән башлап өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документлар формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

3.3. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны күпфункцияле үзәк аша яки күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша кабул итү.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать итә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче күпфункцияле үзәк хезмәткәре:

мөрәҗәгатьнең предметын билгели;

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

Автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазьдә тапшырылган очракта, тапшырылган документларны сканер аша уздыра;

Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаны бастырып чыгара;

тикшереп чыгу һәм имзалау өчен мөрәҗәгать итүчегә бирә;

имзаланганнан соң имзаланган гаризаны Автоматлаштырылган мәгълүмат системасына сканер аша кертә;

электрон формада тапшырылган документларны яки документларның сканер аша уздырылган электрон үрнәкләрен Автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертә, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның оригиналларын кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү буенча язу бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрү өчен әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән электрон формадагы (электрон эшләр пакетлары составында) документлар пакетын мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәкнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән башлап бер эш көне эчендә Министрлыкка тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада кабул итү.

3.3.2.1. Гаризаны электрон формада тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизация уза;

электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5.6 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә җибәрелгән электрон эш.

3.3.3. Министрлык тарафыннан документлар комплектын карау.

3.3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның алынуы административ процедура үтәлешен башлау нигезе булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат – Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече (алга таба – документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат).

3.3.3.2. Мөрәҗәгать итүче гариза белән министрлыкка мөрәҗәгать иткән очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

мөрәҗәгатьнең предметын билгели;

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә (документларның күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүен, документларда чистартылган, өстәп язылган, сызылган сүзләрнең һәм алдан сөйләшенмәгән төзәтмәләр булмавын тикшерә);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазьдә тапшырылган очракта, тапшырылган документларны сканер аша уздыра;

гаризаны бастырып чыгара;

тикшереп чыгу һәм имзалау өчен мөрәҗәгать итүчегә бирә;

имзалаганнан соң, имзаланган гаризаны сканер аша уздыра;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына электрон формада тәкъдим ителгән документларны яки сканер аша уздырылган документларның электрон рәвешләрен кертә, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның оригиналларын мөрәҗәгать итүчегә кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү буенча язу бирә;

гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм «Документларны тикшерү» статусын беркетә, ул Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла;

алынган документларны Министрлык Бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтү вазыйфасы йөкләнгән вазыйфаи затларына (алга таба – Бүлек белгече) карау өчен тапшыра.

Документлар карау өчен алынганнан соң, Бүлек белгече:

алынган электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон үрнәкләрен өйрәнә;

документларның электрон үрнәкләренең комплектлылыгын, укылышлы булуын тикшерә;

Бердәм порталга керү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре

тапшырылган булса).

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларының үтәлмәве ачыкланса, баш тарту турындагы карар проектында аны кабул итү өчен нигез булган 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясындагы пунктлары булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре мондый документларга белдерелә торган таләпләрне бозуга бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту нигезләрендә тапшырылмаган, дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләре булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларның (мәгълүматның, белешмәнең) атамасы турында мәгълүмат күрсәтелергә тиеш), килештерү өчен билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә җибәрелә.

Карар проектын килештерү әлеге Регламентның 3.5.3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булмаса, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат гариза алынган көннән соң бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның алынуы турында теркәү номеры, гаризаны алу датасы, үзенә килгән документларның файллары атамалары исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу датасы күрсәтелгән белдерү җибәрә.

3.3.3.3. Әлеге Регламентның 3.3.3.2 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.3.3.4. Әлеге Регламентның 3.3.3 пунктында билгеләнә торган административ процедуралар гариза карау өчен алынган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: карауга кабул ителгән гариза яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү

3.4.1. Административ процедура үтәлеше өчен вәкаләтле вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан (хезмәткәрдән) мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән документларны алуы административ процедура үтәлешен башлап җибәрү нигезе булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып Бүлек белгече тора.

3.4.2. Бүлек белгече, әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм ведомствоара электрон багланышлар системасы аша (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза карау өчен кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураларны нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларга җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.3. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр (алга таба – документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр), яисә баш тарту турында ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка юлланган белдерү.

3.4.4. Әлеге Регламентның 3.4.2, 3.4.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, шул исәптән гаризаны теркәгән вакыттан башлап, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр) комплектының Бүлек белгеченә алынуы административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Бүлек белгече тора.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләгәндә, Бүлек белгече:

әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре ачыкланса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты әзерли;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булмаса, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре буенча әлеге Регламентның 2.3 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проектын (алга таба – карар проекты) әзерли;

әзерләнгән карар проектын билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерү өчен җибәрә.

Административ процедуралар бер эш көне дәвамында башкарыла.

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын, төзелешкә рөхсәт бирү (төзелешкә рөхсәтк

үзгәрешләр кертү) яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын (алга таба – проектлар) Бүлек җитәкчесе, министр урынбасары, министр тарафыннан килештерү.

Кисәтүләре булган документларның әзерләнгән проектлары Бүлек белгеченә, эшләп бетерү өчен, кире кайтарыла. Кисәтүләре бетерелгәннән соң, документларның проектлары янә килештерү һәм имзалау өчен җибәрелә.

Документларның проектларын имзалаган вакытта министр административ процедураларны үтәү сроклары, аларның эзлеклелеге һәм тулылыгы, электрон документ әйләнеше системасында Министрлыкның вазыйфаи затларыннан килештерүләр булуы өлешендә Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан Регламент үтәлешен тикшерә.

Административ процедураларны үтәү сроклары, аларның эзлеклелеге һәм тулылыгы өлешендә җитешсезлекләр ачыкланган очракта, министр әлеге Регламентның 4.3 пункты нигезендә хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту инициативасы белән чыга.

Административ процедуралар бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту, төзелешкә рөхсәт бирү (төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү) яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

3.5.4. Әлеге Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.5.5. Әлеге Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь вакыты бер эш көне тәшкил итә.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документларның административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан алынуы административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Бүлек белгече тора.

Бүлек белгече:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турындагы белешмәләрне терки һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасының документлар кертелә торган ярдәмче системасына һәм (яки) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасына кертә;

Бердәм портал, Республика порталы аша электрон хезмәттәшлек итү юлы белән мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм

муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат системаларында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе.

3.6.2.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбенә карап, кәгазьдәге электрон документ нөсхәсе белән аңа, алынмалы-куелмалы саклагыч җайланмага яздыру юлы белән, электрон документ нөсхәсе дә бирелә ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

3.6.2.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып җибәрү (бирү).

3.7. Техник хаталарны төзәтү

3.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне җибәрә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 3 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә дә) яисә Бердәм портал, Республика порталы, Министрлык яки күпфункцияле үзәк аша җибәрелә.

3.7.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән гаризаны

терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән датадан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.7.3. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.6 пунктында каралган процедураларны башкара һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып, тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша, Министрлыкка техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында теләсә кайсы мәнфәгатьле заттан гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Бүлек җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Көндәлек тикшереп тору Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламентта һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр үткәрү, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына кагылышлы шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү, алар буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл

кылмавына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Күпфункцияле үзәк карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручы затка (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка) бирелә.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән дәлилләр.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау вакыты – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә

дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача формада яки, аның ихтыярына карап, электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә киләчәк гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңламтамалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.12. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы
кемнән:______________________________________________
(юридик зат-төзүченең атамасы),

______________________________________________
төзелешне, үзгәртеп коруны планлаштыручы;

______________________________________________
ИНН; юридик яисә почта адресы;

______________________________________________
Җитәкченең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефоны;

______________________________________________
банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

## Төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза

Төзүгә/үзгәртеп коруга рөхсәт бирүегез турында үтенәм ______________________________
(кирәклесе астына сызарга);

______________________________________________________________________________
(объектның аталышы)

түбәндәге адрес буенча җир кишәрлегендә:________________________________________________
(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) кадастр номеры: ____________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________ айлык чорга кадәр.

Төзелеш (үзгәртеп кору) түбәндәгегә нигезләнеп гамәлгә ашырылачак: _____елның «___»___________________ №_______________ _______________________________________.
(документ исеме)

Җирдән файдалану хокукы беркетелде ______________________________________________
(документ исеме)

___________________________________________ ____ елның «____»_________ № __________

Объектны төзү өчен проект документлары эшләнде ___________________

___________________________________________________________________________

(проект оешмасының атамасы, ИНН, юридик һәм почта адреслары, җитәкченең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефон номеры, банк реквизитлары

___________________________________________________________________________

(банк атамасы, и-х/с, к/с, БИК)

проект эшләрен башкаруга хокукы бар, түбәндәге белән беркетелгән _______________________

___________________________________________________________________________

(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)

_____ елның «____»______________№______________, һәм билгеләнгән тәртиптә мәнфәгатьле оешмалар һәм архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары белән килештерелде:

– дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмә № _________ _______ елның «___»___________________ алынган.

– җир кишәрлеген планда оештыру схемасы ______________________________________

(оешманың атамасы)

белән килештерелде, ___ елның «___»_________ № __________.

Проект документациясе расланды _______________________________________________

_____________________________________ № ________ _____ елның «___»_______________.

Территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты расланды

_____________________________________ № ________ _____ елның «___»_______________.

(документ исеме)

Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү һәм үзгәртү турында карар кабул ителде____________________________________________________________

(документ исеме)

№ ________ ____ елның «___»_________________

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

Төзүче тарафыннан төзелешне (үзгәртеп коруны) финанслау түбәндәгечә гамәлгә ашырылачак

___________________________________________________________________________

(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр 20___ елның «___»_______________ № _____ килешү нигезендә подряд (хуҗалык) ысулы белән башкарылачак ________________________________________

___________________________________________________________________________

(оешманың аталышы, ИНН,

___________________________________________________________________________

юридик һәм почта адреслары, җитәкчесенең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефон номеры,

___________________________________________________________________________

банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

Төзелеш-монтаж эшләрен башкару хокукы беркетелгән _______________________________

___________________________________________________________________________

(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)

___________________________________________________________________________

«____»____________________ ел, №_______________________

Эшләрне башкаручы итеп____ елның «___»_________ №_______ боерык нигезендә _________________________________________________билгеләнде.

(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

________________________ махсус белеме һәм

(югары, урта)

төзелештә _________ еллык эш стажы бар.

Төзелеш контрольлеге «___»________ ел, № ______________ шартнамә нигезендә түбәндәге тарафыннан гамәлгә ашырылачак:

___________________________________________________________________________

(оешманың атасы, ИНН, юридик һәм

___________________________________________________________________________

почта адресы, җитәкченең исеме, фамилиясе, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефон номеры, банк реквизитлары (банк атамасы, и-х/с, к/с, БИК))

___________________________________________________________________________

заказчы (төзүче) функцияләрен үтәү хокукы беркетелгән ____________________________

___________________________________________________________________________

(документ исеме һәм аны биргән оешма аталышы)

№ _____________ «____»____________________ ел.

Әлеге гаризада китерелгән белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр турында ______________________________ хәбәр итәргә сүз бирәм.

(вәкаләтле орган атамасы)

Төзелеш өчен рөхсәтне Министрлыкта / КФҮ электрон рәвештә алам

(кирәклесе астына сызарга);

___________________________________________________________________________

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда да, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне дә кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, файдалана алмаслык итүгә, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) үз ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның риза булуы хакында раслыйм.

_____________________ (вазыйфа) _________________ (имза) ______________________ (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

«___»______________20_____ ел.

Мөһер урыны (булган очракта)

Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

кемнән:______________________________________________

(юридик зат-төзүченең атамасы),

_____________________________________________________

төзелешне, үзгәртеп коруны планлаштыручы;

_____________________________________________________

ИНН; юридик яисә почта адресы;

_____________________________________________________

Җитәкченең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефоны;

_____________________________________________________

банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

## Төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озынайтуга бәйле рәвештә төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза

_______________________________________________________________________________

(объектның аталышы)

төзүгә/үзгәртеп коруга 20___ елның «_____»___________№ ____ рөхсәтнең гамәлдә булу
(кирәклесе астына сызарга)

чорын озынайтуыгызны сорыйм.

Түбәндәге адрес буенча җир кишәрлегендә урнашкан: ______________________________________

(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

____________________________ айлык чорга кадәр.

Төзелеш (үзгәртеп кору) түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

________________________ «____» _____________________ ел, № ___________________.

(документ исеме)

Җирдән файдалану хокукы беркетелде ___________________________________________________

(документ исеме)

__________________________________________ _____ елның «____»_________ № __________

Объект төзелешенең проект документлары эшләнде _____________________________________

_______________________________________________________________________________

__ (оешманың аталышы, ИНН, юридик һәм почта адреслары,

_______________________________________________________________________________

җитәкченең исеме, фамилиясе, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефон номеры, банк реквизитлары

_______________________________________________________________________________

(банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

____________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)

_____ елның «____»______________№______________, һәм билгеләнгән тәртиптә мәнфәгатьле Оешмалар һәм архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары белән килештерелде:

– дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмә № _________ _______ елның «___»__________________ алынды.

Җир кишәрлеген планда оештыру схемасы ______________________________________
(оешманың атамасы)
белән килештерелде, ___ елның «___»_________ № __________.

Проект-смета документациясе расланды _____________________________________

_______________________________________ № ____, ___________елның «___» _______________.

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

Төзүче тарафыннан төзелешне (үзгәртеп коруны) финанслау түбәндәгечә гамәлгә ашырылачак ________________________________________________________________________
(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр 20___ елның «___»______________ № _____ шартнамә нигезендә подряд (хуҗалык) ысулы белән башкарылачак.

____________________________________________________________
(оешма атамасы, ИНН,
____________________________________________________________
юридик һәм почта адреслары, җитәкчесенең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефон номеры,
____________________________________________________________
банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

Төзелеш-монтаж эшләрен башкару хокукы беркетелгән
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)
____________________________________________________________

«_____»____________________ ел, №_______________________

Эшләрне башкаручы итеп____ елның «___»__________ №_______ боерык нигезендә_________________________________________ билгеләнде.
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
___________________________ махсус белеме бар һәм төзелештәге эш стажы ___ ел.
(югары, урта)

Төзелеш контрольлеге «___»________ ел, № _____________ шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла
____________________________________________________________
(оешманың аталышы, ИНН, юридик һәм
____________________________________________________________
почта адресы, җитәкченең исеме, фамилиясе, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефон номеры, банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

заказчы (төзүче) функцияләрен үтәү хокукы беркетелгән ________________________________
____________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән оешма аталышы)

№ _____________ «____»____________________ ел.

Әлеге гаризада китерелгән белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр турында ___________________________ хәбәр итәргә сүз бирәм.
(вәкаләтле орган атамасы)

Гамәлдә булу срогын озайтуга бәйле рәвештә, төзелешкә булган рөхсәтне кертелгән үзгәрешләре белән Министрлыкта/ КФҮ/ электрон рәвештә алам.
(кирәклесе астына сызарга);

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда да, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында

карарлар кабул итүне дә кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, файдалана алмаслык итүгә, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) үз ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның риза булуы хакында раслыйм.

| ______________________ | ____________________ | _________________________ |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) |

«___»______________20_____ ел.
Мөһер урыны (булган очракта)

Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

кемнән:______________________________________

(юридик зат-төзүченең атамасы),

______________________________________

төзелешне, үзгәртеп коруны планлаштыручы;

______________________________________

ИНН; юридик яисә почта адресы;

______________________________________

Җитәкченең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефоны;

______________________________________

банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

## Техник хата төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ______________________________________

(хезмәтнең аталышы)

Язылган:______________________________________

Дөрес белешмәләр:

______________________________________

______________________________________

Техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Кабул ителгән карар нәтиҗәсен (төзәтелгән документны яки баш тарту турында белдерүне) түбәндәгечә җибәрүегез турында үтенәм:

e-mail:______________________ адресына электрон документ рәвешендә җибәрүне;

кәгазьдә почта юлламасы итеп түбәндәге адрес буенча:

Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы
кемнән:______________________________________
(юридик зат-төзүченең атамасы),

______________________________________________
төзелешне, үзгәртеп коруны планлаштыручы;

______________________________________________
ИНН; юридик яисә почта адресы;

______________________________________________
Җитәкченең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта), телефоны;

______________________________________________
банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

## Техник хата төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
______________________________________________________________
(хезмәтнең аталышы)

Язылган:______________________________________________________

Дөрес белешмәләр:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

Техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Кабул ителгән карар нәтиҗәсен (төзәтелгән документны яки баш тарту турында белдерүне) түбәндәгечә җибәрүегез турында үтенәм:

e-mail:________________________________ адресына электрон документ рәвешендә җибәрүне;

кәгазьдә почта юлламасы итеп түбәндәге адрес буенча:

Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

(Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган бланкы)

Кемгә

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме – гражданнар һәм ШЭ өчен)*

*(оешманың тулы исеме – юридик затлар өчен)*

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар

Дата ______________ № ____________

_________________ (*мөрәҗәгать итүче*) _____________ № _______ мөрәҗәгате нигезендә, __________________________ бәйле рәвештә (*баш тарту нигезе*), хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде.

Баш тарту сәбәбен дәлилле нигезләү: _____________.

Өстәмә рәвештә хәбәр итәбез:
_____________________________________________ (*баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә*).

Документларны кабул итүдән баш тарту дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, кабат мөрәҗәгать итүгә каршылык була алмый.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

_____________________________________________ _____________________________

(*карар кабул итүче органның вәкаләтле затының вазыйфасы*) (*имза*) (*инициаллары*)

Электрон имза турында белешмәләр

Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы хакимият органнары (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министрның беренче урынбасары | **231-14-03** | Aleksey.Frolov@tatar.ru |
| Министр урынбасары | **231-15-07** | Vladimir.Kudryashev@tatar.ru |
| Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе җитәкчесе | **231-15-57** | Asiya.Tazetdinova@tatar.ru |
| Территорияләрне планлаштыру һәм төзү бүлеге башлыгы | **231-15-16** | Olga.Kaynova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестицияләү программаларын гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе | **264-77-24** | Yuriy.Azin@tatar.ru |